**Татарстан Республикасы**
**Лениногорск муниципаль районы**
**Түбән Чыршылы авыл җирлеге**
**Мордва Ивановкасы авылында гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

2021 елның 21 ноябре № 6

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Түбән Чыршылы авыл җирлегенең Мордва Ивановкасы авылында 2022 елда үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Түбән Чыршылы авыл җирлеге Мордва Ивановкасы авылы гражданнары җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елда гражданнарның үзара салымын Лениногорск муниципаль районы Түбән Чыршылы авыл җирлеге Мордва Ивановкасы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, беренче төркем инвалидлар, сугыш ветераннары, көндезге формада белем алучы студентлар, хәрби хезмәт үтүче гражданнардан тыш, 400 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту, әлеге кагыйдәләргә туры китереп, җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- Мордва Ивановкасы авылында Ленин урамы, Совет урамнарын яктыртуга техник хезмәт күрсәтү.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Түбән Чыршылы авылы, Түбән Чыршылы авылы административ бинасында-Үзәк урамы, 105 йорт, балалар бакчасы бинасында-Совет урамы, 8 йорт, Үзәк урамы, 23нче йорт янында, «АФ-Спартак» ҖЧҖ идарәсе бинасында-Совет урамы, 2нче йорт , Югары Чыршылы авылында-авыл клубы бинасында-Горная урамы, 27нче йорт, Мордва Ивановкасы авылында-Совет урамы, 13нче йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) "Авыл җирлекләре" бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Түбән Чыршылы
авыл җирлеге башлыгы Н.Я.Хәйруллина